УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.02.2016 г.Казань 01-05/42-пр

«Татарстан Республикасы үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында» 2015 елның 23 июнендәге № 01-05/100-пр боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм бүтән затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килүе турында хәбәр итүләре тәртибе хакында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге № 650 Указы нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1. «Татарстан Республикасы үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында» 2015 елның 23 июнендәге № 01-05/100-пр боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерык исемендә «үзйөрешле машиналар» сүзләре алдыннан «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

Боерыкның 1 пунктында «үзйөрешле машиналар» сүзләре алдыннан «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

Татарстан Республикасы үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең дәүләт граждан

хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында 2015 елның 23 июнендәге № 01-05/100-пр боерык белән расланган нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) исемендә «үзйөрешле машиналар» сүзләре алдыннан «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

Нигезләмәнең 1 һәм 2 пунктларында «үзйөрешле машиналар» сүзләре алдыннан «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

3 пунктының «а» пунктчасында «үзйөрешле машиналар» сүзләре алдыннан «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

15 пунктның «б» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турындагы хәбәрнамәсе;»;

түбәндәге эчтәлекле 16.1 пунктча өстәргә:

«16.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктның «б» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә Идарәнең дәүләт хезмәте, кадрлар, эшләр алып бару һәм хокукый тәэмин итү секторының коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карала, ул исә хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерли.»;

17 пункттан дүртенче җөмләне төшереп калдырырга;

19 пункттан икенче җөмләне төшереп калдырырга;

20 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) 10 көнлек срокта комиссия утырышы датасын билгели. Бу чакта комиссия утырышы датасы әлеге мәгълүмат кергән көннән 20 көннән дә соңрак булырга тиеш түгел, әлеге Нигезләмәнең 21 һәм 22 пунктларында каралган очраклардан гайре;»;

21 пунктта «өченче абзацта күрсәтелгән гариза» сүзләрен «өченче һәм дүртенче абзацларда күрсәтелгән гаризалар» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 22.1 пунктча өстәргә:

«22.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктның «б» пунктчасындагы икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яисә әлеге Нигезләмәнең 15 пунктның «б» пунктчасындагы бишенче абзацында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләрне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләгәндә, Идарәнең дәүләт хезмәте, кадрлар, эшләр алып бару һәм хокукый тәэмин итү секторының коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты – мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә керткән дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә уздырыга, аңардан язмача аңлатмалар алырга, ә Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсе башлыгы яисә

аның урынбасары, шуңа махсус вәкаләт тапшырылган зат билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрергә хокуклы. Мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә кергәннән соң җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Гарызнамәләр җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә кергән көннән 45 көн эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Әлеге срок озайтылырга да мөмкин, әмма бу 30 көннән дә артык булмаска тиеш.»;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, үзенә карата хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү хакындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре яисә Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче граждан барында уздырыла. Дәүләт хезмәткәренең яисә гражданның комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында әлеге Нигезләмәнең 15 пунктның «б» пунктчасы нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә яисә хәбәрнамәдә күрсәтелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 23.1 пунктча өстәргә:

«23.1. Комиссия утырышлары түбәндәге очракта дәүләт хезмәткәре яисә граждан барында уздырылырга мөмкин:

а) әлеге Нигезләмәнең 15 пунктның «б» пунктчасында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә дәүләт хезмәткәренең яисә гражданның комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте хакында күрсәтүләр булмаган;

б) комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләгән һәм утырышны уздыру вакыты һәм урыны турында үз вакытында тиешенчә хәбәр ителгән дәүләт хезмәткәре яисә граждан комиссия утырышына килмәгән.»;

түбәндәге эчтәлекле 30.1 пункт өстәргә:

«30.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктның «б» пунктчасындагы бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге караларның берәрсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты булмауны танырга;

б) дәүләт хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуының мәнфәгатьләр конфликтына китерүен яисә китерергә мөмкин булуын танырга. Бу очракта комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яисә) Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсе башлыгына мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуны яисә мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килүне булдырмый калуны тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәренең мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәвен танырга. Бу очракта комиссия Татарстан

Республикасы Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсе башлыгына дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрүне тәкъдим итә.»;

40 пунктта «3 көнлек срокта» сүзләрен «7 көнлек срокта» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык Р.Р. Зыятдинов